КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 17

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1097 нче, 2014 ел, 31 декабрь, 1096 нчы, 2015 ел, 6 ноябрь, 325 нче, 2015 ел, 12 ноябрь, 847 нче, 2016 ел, 1 март, 127 нче, 2016 ел, 4 июнь, 372 нче, 2017 ел, 12 май, 276 нчы,

2017 ел, 29 июль, 529 нчы, 2017 ел, 28 август, 609 нчы, 2018 ел, 18 июнь, 493 нче, 2018 ел, 12 сентябрь, 773 нче, 2018 ел, 25 декабрь, 1218 нче, 2019 ел, 7 сентябрь, 800 нче, 2019 ел, 16 декабрь, 1154 нче, 2020 ел, 25 август, 731 нче, 2020 ел, 9 октябрь, 915 нче, 2020 ел, 25 декабрь, 1192 нче, 2021 ел, 6 сентябрь, 811 нче, 2021 ел, 25 сентябрь, 914 нче, 2022 ел, 22 гыйнвар, 38 нче, 2022 ел, 17 май, 452 нче, 2022 ел, 27 июнь, 611 нче, 2023 ел, 15 апрель, 471 нче, 2023 ел, 01 август, 927 нче, 2023 ел, 30 август, 1041 нче, 2023 ел, 10 октябрь, 1290 нчы, 2023 ел, 2 декабрь, 1548 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә, 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5.3. Социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасы булган бүлекләрендәге һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасы булган гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү бүлекләрендәге социаль хезмәтләр күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) бәясенә, хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт өчен түләү фондына, персоналның штат саны нормативларына карата 53 нче таблица нигезендә кабул ителә торган төзәтү коэффициенты.

53 нче таблица

| Оешма төре, социаль хезмәт күрсәтү формасы | Халык саны, мең кеше | Социаль хезмәтләр күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) бәясенә, хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт өчен түләү фондына һәм персоналның штат саны нормативларына карата төзәтү коэффициентлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасы | | социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасы | |
| | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| Социаль хезмәт күрсәтү комплекс-лы үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасы булган бүлекләре һәм социаль хезмәт | 13,8 гә кадәр | 1,120 | 1,150 | 1,120 | 1,120 |
| | 13,8 дән 15,4 кә кадәр | 1,120 | 1,120 | 1,120 | 1,120 |
| | 15,4 тән 20,5 кә кадәр | 1,000 | 1,080 | 1,000 | 1,010 |
| | 20,5 тән 21,6 га кадәр | 1,000 | 1,040 | 1,000 | 1,010 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| күрсәтүнең ярым-стационар формасы булган гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү бүлекләре | 21,6 дан 39,0 га кадәр | 1,000 | 1,000 | 1,000 | 1,010 |
| | 39,0 дән 41,5 кә кадәр | 1,000 | 0,919 | 1,000 | 1,000 |
| | 41,5 тән 58,0 гә кадәр | 1,000 | 0,760 | 1,000 | 0,970 |
| | 58,0 дән 71,0 гә кадәр | 0,960 | 0,760 | 1,000 | 0,970 |
| | 71,0 дән 101,0 гә кадәр | 0,960 | 0,760 | 0,900 | 0,970 |
| | 101,0 дән 501,0 гә кадәр | 0,960 | 0,760 | 0,790 | 0,970 |
| | 501,0 дән 601,0 га кадәр | 0,650 | 0,760 | 0,725 | 0,970 |
| | 601,0 дән һәм аннан югары | 0,570 | 0,760 | 0,617 | 0,970». |

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин